# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 8 июлендә
кабул ителде

Әлеге Закон Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

1 статья. **Әлеге Законның гамәлдә булу даирәсе**

1. Әлеге Закон «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2008 елның 22 декабрендәге 262-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә кабул ителде һәм Федераль закон белән җайга салынмаган өлештә Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү үзенчәлекләрен билгели.

2. Әлеге Законның гамәлдә булуы Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагыла.

2 статья. **Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар, Федераль закон һәм суд эшләрен башкару тәртибен, җәмәгать судьяларының

вәкаләтләрен һәм эшчәнлек тәртибен билгели торган федераль законнар, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, башка Татарстан Республикасы законнары, шулай ук Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү рәвеше һәм теле**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүмат телдән һәм документлаштырылган мәгълүмат рәвешендә, шул исәптән электрон документ рәвешендә дә, бирелергә мөмкин.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүмат, әгәр гарызнамәдә аларның эшчәнлеге турында мәгълүмат бирүнең башка алымы билгеләнмәгән булса, мәгълүматтан файдаланучының язма гарызнамәсенә җавап итеп, язма рәвештә бирелә.

3. Күрсәтелгән мәгълүматны соратыла торган рәвештә бирү мөмкинлеге булмаганда, мәгълүмат булган рәвешчә бирелә. Мәгълүматтан файдаланучыга мәгълүматны соратыла торган рәвештә бирү мөмкинлегенең булмавы турында мәгълүматны мәгълүматтан файдаланучы тарафыннан күрсәтелгән рәвештә бирә алмауның сәбәбен күрсәтеп хәбәр ителергә тиеш.

4. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүмат гражданнарга (физик затларга), шул исәптән оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләренә, кабул итү вакытында телдән бирелә.

5. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүмат гомуми файдаланудагы элемтә челтәрләре аша, шул исәптән телефон аша да, тапшырылырга мөмкин.

6. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә бирелә.

4 статья. **Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны оештыру**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану җәмәгать судьясы аппаратындагы җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан тәэмин ителә.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы эшчәнлеге турында мәгълүматны биргән өчен җаваплы затлар Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы тарафыннан билгеләнеп куела.

3. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы эшчәнлеге турындагы мәгълүмат гомуми файдаланудагы мәгълүмат системаларында, шул исәптән Интернет челтәрендә, шулай ук Федераль закон нигезендә җәмәгать судьясы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы бинасында урнаштырыла.

5 статья. **Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында Интернет челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүматтан файдалануны оештыру**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен Интернет челтәреннән файдаланалар, анда, гарызнамәне җибәреп була торган электрон почта адресын күрсәтеп, үзләренең рәсми сайтларын булдыралар.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының рәсми сайтларын булдыру тәртибе Федераль закон нигезендә билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының рәсми сайтларындагы мәгълүмат Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

4. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының рәсми сайтларыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан күрсәтелә торган тәртиптә билгеләнә.

6 статья. **Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү, әлеге статья нигезләмәләрен исәпкә алып, Федераль законның 3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Федераль закон нигезендә бастырып чыгарылырга тиешле суд актлары текстлары, Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән суд актлары текстларыннан тыш, Интернет челтәрендә тулы күләмдә урнаштырыла.

3. Файдаланучыларны Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында архив фондларындагы мәгълүмат белән таныштыру архив эше турында Россия Федерациясе законнарында һәм шулар нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә, шулай ук архив эше турында Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының шулар нигезендә кабул ителә торган башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

7 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 24 июле
№ 55-ТРЗ